Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Урта Камышлы авыл җирлеге Урта Камышлы торак пунктында гражданнар җыены КАРАРЫ

**15 ноябрь 2022 ел** **№ 2**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Урта Камышлы авыл җирлеге Урта Камышлы торак пункты гражданнары җыены

КАРАР ИТТЕ**:**

1. Урта Камышлы авыл җирлегенең Урта Камышлы авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 2023 елда 1000 сум күләмендә үзара салым кертергә һәм җыелган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә белән килешәсезме:

1. Су белән тәэмин итү чыганакларына норматив таләпләрне тәэмин итү буенча эшләр үткәрү;
2. Урта Камышлы торак пункты чикләрендә авыл эчендәге юлларны ремонтлау;
3. Зират коймаларын ремонтлау һәм карап тоту;
4. Урам утларын ремонтлау;
5. Иҗтимагый киңлекне төзекләндерү;
6. Янгынга каршы куркынычсызлыкның норматив таләпләрен тәэмин итү буенча эшләр үткәрү

Халык җыенында рәислек итүче: В.П. Вафина
Урта Камышлы авыл җирлеге башлыгы: В.П. Вафина